**Карар № 91**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге Советы

Таш-Чишмә авылы 13 июнь 2024 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 апрелендәге 63 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Төбәк салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Өҗем авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Өҗем авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 апрелендәге 63 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1 1 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:
«5) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар өчен 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнә торган бурыч булу;»;

1.2. 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:
«6) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар узгач, физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адреслары буенча һәм җирлектәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Тарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге башлыгы: А.Т.Вәлиев